УДК 930.2 DOI: 10.22378/he.2019-4-2.284-293

# «МИЛЛИ БАЙРАК» ГАЗЕТАСЫНДА РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН ЭШЧӘНЛЕГЕ ЯКТЫРТЫЛЫШЫ

***Ш.Ф. Садыйков***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*mergen777@mail.ru*

Күренекле галим, педагог, тарихчы һәм дин әһеле Ризаэтдин Фәхретдин исеме татарлар арасында гына түгел, ә барлык мөселман дөньясы өчен таныш. Аның белем өлкәсе күпкырлы һәм уникаль, дини эшчәнлек белән беррәттән, ул актив рәвештә мәгърифәтчелек һәм нәшрият эшчәнлеген алып барган. Әлеге мәкаләдә Япониядә ун ел дәвамында (1935–1945) басылып килгән «Милли Байрак» газетасында Р. Фәхретдин эшчәнлегенә карата басылып чыккан кайбер материаллар карала. Мөфти буларак, Р. Фәхретдин илдәге барлык төрки-мөселман халыкларының иҗтимагый фикер үсешендә һәм мәдәниятендә үзәк урыннарның берсен алып тора. Аның даны бөтен төрки, хәтта ислам дөньясында һәм Аурупа илләрендә киң таралган була. Әлеге шәхеснең шундый абруена карамастан, совет матбугатында аның вафаты турында бер хәбәр дә басылып чыкмый. Бу чорда чит ил матбугаты Россиядә барган процессларны бәяләүдә һәм яктыртуда күпкә мөстәкыйль була. «Милли Байрак» газетасында Р. Фәхретдингә багышланган материалларны өйрәнү аның татар мәгърифәтчелек үсешенә керткән өлешен, тормыш юлын, ислам дөньясының эшчәнлегенә мөнәсәбәтен билгеләргә, объектив рәвештә бәяләргә һәм шуның белән аның татар милләте язмышында олуг шәхес булуын ассызыкларга мөмкинлек бирә.

**Ачкыч сүзләр:** Ризаэтдин Фәхретдин, мөфти, «Милли байрак» газетасы, вакытлы матбугат, татар милләте, Ерак Көнчыгыш, төрки дөнья

**Цитата өчен:** Садыков Ш.Ф. «Милли байрак» газетасында Ризаэтдин Фәхретдин эшчәнлеге яктыртылышы // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 2. С. 284–293. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.284-293

2019 ел татар халкының үсешенә зур өлеш керткән олуг галимнәребез юбилейларына бай. Алар арасында тарихыбызда тирән эз калдырган күренекле шәхесебез – мәгърифәтче, галим, педагог, тарихчы, мөфти һәм дин әһеле – Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) дә бар. Бүгенге көндә аның тормышын, эшчәнлеген һәм көнкүрешен яктырткан хезмәтләр шактый. Әлеге мәкаләдә «Милли Байрак» газетасында Р. Фәхретдингә багышланган мәгълүматлар белән уртаклашасыбыз килә. «Милли Байрак» газетасы – Ерак Көнчыгыш татарларының ихтыяҗларын яктыртучы даими чыгып

килгән вакытлы матбугат чарасы. Аның дөнья күрүе Гаяз Исхакый исеме белән бәйле (Аурупага күчкәннән соң аның мөхәррире итеп Ибраһим Дәүләт-Килди билгеләнә). Әлеге газета 1935 елның 1 ноябреннән 1945 елның 20 мартына кадәр чыга. Бу вакыт аралыгында 400 сан дөнья күрә. Киң таралышына карамастан, әлеге басма СССР территориясендә таралмый [3, 4 б.].

Р. Фәхретдин исеме белән бәйле мәкаләләр әлеге газетада шактый урын алган. Әмма күпчелеге аның 1936 елдагы вафаты белән бәйле. «Милли байрак» газетасының 30 нчы саны тулысынча Р. Фәхретдингә багышланган. Монда аның гыйльми эшчәнлеген, хезмәтләрен һәм төрек-татар дөньясына керткән өлешен бәяләүдән тыш, әлеге шәхеснең Ерак Шәрыкта да зур абруйга лаек булуы ассызыклана. Бу иң беренче чиратта Токио, Нагоя, Фузанда, Киҗуда, Тянсзин, Мукден, Кобе, Харбин, Синзин шәһәрләрендә бу көннең мөселманнар тарафыннан матәм көне итеп билгеләнүендә күренә. Моннан тыш, әлеге санда аның рухына һәм олуглыгына багышланган аерым шигырьләр дә китерелә. Бу Солтан исеме белән имзаланган авторның «Риза хәзрәт», Арсланбәк дигән кешенең «Тагын бер корбан» һәм Заһидәнең «Олуг мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренә багышлана» исемле шигырьләре. Газетада Ризаэтдин Фәхретдинның «Дини вәгазь», «Олуг мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең мәктүбләре», «Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең Шиһабетдин Әл-Мәржани хакында кайбер язулары» һәм башка мәкаләләр урын алган. Болар күбесенчә аның «Шура» журналында чыккан мәкаләләре. Без иң беренче чиратта Р. Фәхретдиннең вафаты белән бәйле булган кайбер мәкаләләргә игътибар итәргә булдык.

XX гасырның 20–30 елларында дингә карата сәясәт үзгәргәч, күп кенә дин әһелләре, милли хәрәкәттә катнашучы интеллигенция бик зур эзәрлекләүләргә, репрессияләргә дучар була. Аларның исемнәре озак елларга онытылып кала. Диния нәзарәтенең башлыгы Р.Фәхретдинның вафаты турындагы мәгълүмат Россиянең матбугат битләрендә яктыртылыш тапмый, киресенчә тавышсыз уздырыла. Совет чорында хакимият үзенә кирәкле караш тудыра дигән фикергә 1979 елда З.А. Ишмөхәммәтовның «Социальная роль и эволюция ислама в Татарии» исемле китабы ачык мисал булып тора. Автор китабында милли хәрәкәттә катнашкан дип дин әһелләрен, шул исәптән Р. Фәхретдинне да буржуаз милләтчелектә гаепли, аларның иҗатларына һәм эшчәнлекләренә реакционлык мөһире суга. Туганнары һәм аерым белгечләр тарафыннан әлеге бәяләмәне төшереп калдыру буенча омтылышлары бернинди нәтиҗә бирми [1, 102 б.]. Шунлыктан әлеге тоталитар чикләүләрдән читтә булган һәм үз фикерләрен иркле, мөстәкыйль белдерә алган авторларының карашларын өйрәнү Р. Фәхретдинның ул вакыттагы эшчәнлегенә объектив бәя бирергә мөмкинлек бирә.

Р. Фәхретдинның мөселман дөньясында ихтирам ителүе турында аның хакында чит илләрдә басылган мәкаләләр сөйли. «Милли байрак» газетасының Тимур исемле автор тарафыннан язылган «Мөфти Ризаэтдин

бине Фәхретдин хәзрәтләре хакында ислам вә алман матбугаты» мәкаләсе моның ачык мисалы. Автор монда Мисырда чыга торган «Әл-Балаг» газетасының 16 сентябрь (1936 ел) басмасыннан өзек тәкъдим итә. Бу мәкаләнең авторы Каһирәдә яшәүче Хәмзә Таһирбәк була. Әлеге мәкаләдә Р. Фәхретдинның эшчәнлеге һәм ислам дөньясындагы роле ассызыклана. Моннан тыш, Тимур Лахурдада чыга торган «Ихсан» газетасының 14 октябрь санының, мөфти хәзрәт хакында язылган мәкаләнең (идарәгә килгән) кыскача эчтәлеген биреп уза. Мәкалә хәзрәтнең Уфа шәһәренә килеп эләгүеннән башлап, «Вакыт», «Шура» журналларындагы эшчәнлеген үз эченә ала. Р. Фәхретдин тарафыннан журналда бастырылган аерым шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләрен һәм аның гыйльми әсәрләрен аерым бүлекләргә бүлеп күрсәтә. Р. Фәхретдинның большевиклар кулыннанниләр күрүенә туктала һәм аның кичергән авырлыкларын тасвирлар өчен аның хатларын тәрҗемә итә. «Мәрхүмнең рухына дога кылып үтим һәм аның кебек бөек дин башлыгы бирсен», – дигән сүзләре белән тәмамлый [5, 2 б.].

«Мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләре хакында ислам вә алман матбугаты» мәкаләсендә Дәһлидә чыга торган «Әл Җәмгыя», «Заминдар», «Мәдәния» исемле газеталар да искә алына һәм аларда мөфти хәзрәт хакында рәсемнәр белән бирелеп, озын мәкаләләр басылуы турында әйтелә.

«Милли байрак» белән берлектә «Милли юл» мәҗмугасы үзләренең бер саннарын мәрхүмнең исеменә багышлап чыгарулары һәм ислам матбугатларында мөфти хәзрәтенең вафаты хакында язылуы турында хәбәр ителә.

Алман матбугатына килгәндә, Тимур, «Ост Европа» мәҗмугасының август – сентябрь саннарында, Бертольд Шпулерның СССР мөселманнарының дини башлыкларының үлеме белән бәйле булган мәкаләнең кыскача эчтәлеген тәкъдим итә. Бу мәкалә мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең вафаты, Русиядә яшәүче мөселманнар өчен никадәр зур югалту булуыннан башлап, төрки-татар мөселманнарына әдәби-сәяси һәм тәрбияви хезмәт күрсәткән галимне югалтулары ислам дөньясы өчен, Русиядә яшәүче төрки халыкларга караганда да зуррак икәнең аерым ассызыклый. Төрек милләтчелеге белән ислам диненең тирәнтен бәйләнүе хакында фикер алышып, Русиядә яшәүче төркиләренең тормышы госманлы төрекләреннән бөтенләй башка булуын күрсәтә. Госманлы төрекләренең иң зур җинүен ул, милләт нигезендә берләшеп, бүгенге Төркия җөмһүриятен коруларында дип саный. Русиядә хакимият дингә, милләткә каршы булганга, дин нигезендә берләшүдә Диния нәзарәтенең мөселманнар өчен әһәмиятле булуын билгели һәм Р. Фәхретдиннең дин башлыгы буларак чын милләт җитәкчесе урынын алуын бәян итә. Шул караштан чыгып большевикларның исламияткә, төркичелеккә каршы килүләрен һәм совет хакимиятенең русия төркиләренең иң беренче дәрәҗәдә көчле бер көч булган мөфти хәзрәтләренең вафатын мөмкин кадәр тавышсыз-тынсыз гына уздырырга тырышулары Р. Фәхретдиннең төрки кыйблаларны бер-

ләштерүдә зур роль уйнавын күрсәтә. Советларның мөфти вафатыннан соң да аның үлеме тәэсиреннән куркуларын ассызыклап, Русия төркиләре өчен бу галимнең вафаты нинди зур югалту икәнен билгеләп, мәкаләсен тәмамлый [5, 2 б.].

«Милли байрак» газетасындагы мәкаләләрне укыганда, аларның рус цензурасыннан бәйсез булуы күзгә ташлана. Бу иң беренче чиратта милли темаларны, вакыйгаларны яктыртуда күренә. Мәсәлән, Русия әсире төреклеге; милләтебезне җимерелүенә каршы фидакарь хезмәт алып бару; иле таланган, милли минлеге хур ителгән халык; коллык тормышыннан чыгу; большевикларының мәгънәви зинданында гомер итүе; илебезне тоткынлыкта тотучы Совет иле; Русия коллыкка төшергән милләтләрне, милли-мәгънәви мәсьәләләрдә аякка бастыру һәм башка сүзтезмәләр киң кулланыла. Моннан тыш, мәкаләләрдә еш кына бәйсезлек сүзе белән беррәттән мөстәкыйльлек, мохтарият, истикляль кебек синонимнар урын алган.

Р. Фәхретдин турында мәкаләләр авторлары, аның мөхәррирлек елларында матбугат битләрендә чыккан хезмәтләренең бүгенге көндә кулларында юклыгына ачыналар. Алар фикеренчә, аның бөтен иҗатын, әсәрләрен белмичә, аннан-моннан кулга эләккән материалларга таянып кына хезмәтен бер үлчәүгә салу җиңел мәсьәлә түгел [5, 2 б.].

Икенче мәкалә «Мәрхүм мөфтиебез Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтенең газиз рухына» дип атала. Аның авторы – әлеге газетаның төп хезмәткәре Рокыя Мәхәммәдиш. Бу мәкалә Солтан исемле авторның икеюллык шигыре белән башлана:

Милләт белән динне үрнәк итеп,
Хезмәт итте иле, дин, милләт өчен.

Әлеге мәкалә Ризаэтдин Фәхретдин вафатына биш ел тулу уңаеннан бастырыла. Автор большевикларның мәгънәви зинданда гомер итүче, соңгы елларында моңа кушылган ачлык, мохтаҗлык эчендә вафат булган мөфти Ризаэтдин бин Фәхретдин хәзрәтләре халкыбызның күңелендә калуын һәм өметләрен үзендә гәүдәләндергән бөек шәхесләрнең берсе булуын ассызыклый. Рокыя Мәхәммәдиш «Диния нәзарәте»нең оешуын һәм Русия мөселман халкы өчен коллыктан чыгу, үз дәүләтчелеген торгызу кыйбласы булуын күрсәтә. Диния нәзарәтенең халык арасында хөрмәт һәм мәхәббәт казануын ул Р. Фәхретдин исеме белән бәйли. Үз сәләте, тырышлыгы һәм шәхеслеге белән хезмәт күрсәткән Р. Фәхретдин «казый» исеменә лаек була. «Риза казый» Диния нәзарәтенең эшләрен тәртипкә куюы, халык аңлардлык әмерләр таратып, мәхәлләләрне нәзарәтка баглау аркылы дини эшләрен берлек җебенә тоташтыручы булуын күрсәтә. Казый булып торган елларында ук Ризаэтдин хәзрәттә халыкны уяту, агарту һәм милли аң тирәсендә милләтне берләштерү омтылышы туып, бу омтылыш олуг остазның бөтен гомере дәвамындагы эшләренең нигезе булын билгели.

Автор аның Диния нәзарәтендәге иске язуларын, эш дәфтәрләрен тәртипкә салуын, тарихны, үткәнне өйрәнүне, халкыбызны коллык караңгысыннан чыгару өчен чит мәдәниятләргә игътибар итүен, Ш. Мәрҗани

һәм К. Насыйри дәвамчысы булуын бәян итә. Русия астындагы төрки өлкәләрдә коллыкны бетерү юлында хезмәт итүе белән Исмәгыйл Гаспралы, Йосыф Акчуралар белән кулга-кул тоташып, милләтне агарту, уяту юлында хезмәт итүен күрсәтә. Ул милли-мәгънәви яктан коллыкка төшкән милләтне, башка милләтләр белән буй үлчәшә алырлык хәлгә китерү, милли мөстәкыйльлек хисен булдыру юлында зур эш куйган шәхес, ди автор.

Русиянең японнар тарафыннан җиңелүе мәрхүм мөфтиебезнең язу эшенә күчүенә сәбәп була. 1905 елда Идел-Урал милли матбугаты оешкан вакытта, казый булып торган Ризаэтдин Фәхретдиннең сәләтле каләменә киң алан ачыла. 1907 елда «Вакыт» газетасы янында чыга башлаган «Шура» мәҗмугасы мәрхүмне казыйлыгыннан аера. Большевик баш күтәрүенә кадәр ун ел буе чыгып торган «Шура» мәрхүмнең борынгы бөекләребезнең тормышларына, ислам дөнясының мәшһүр адәмнәренә багышланган язулары «Асар» га киң мәйдан ачу белән бергә халкыбызның миллимәгънәви хәятенең барометры төсенә әверелә. Монда Р. Фәхретдиннең милли тәрбиядән башлап халкыбызның бөтен тормышына караган язмалары янында ул чорлардагы зыялаларыбыз һәм язучыларыбызның мәкаләләре урын алалар.

Мөхәрир Р. Фәхретдиннең бай каләменә ике атнага бер чыга торган бу мәҗмугада бик тар урын булганга, балалар өчен язылган дәреслекләре, яшьләрнең милли тәрбиясенә, хатын-кызларның гаилә тормышына һәм гомум милләт үлчәвендә торткан урыннарына багышлап язылган китаплары, нәсыйхәт вә дин мәсьәләләрен эченә алган әсәрләре аерым рәвештә басылып баралар.

Ерак Шәрыкта, чит илләрдә яшәүче мөһаҗирләр моннан биш ел элек большевик хөкүмәте мәсхәрәләреннән, халкыбызның дини, милли явызлыгын күкрәге белән калкан шикелле саклап килгән мөфти Р.Фәхретдин хәзрәтләренең вафаты хәбәреннән тирән кайгыда кала. Чөнки мәрхүм мөфтиебез халкыбызның милли минлеген саклавын, милли барлык дәрәҗәсен күтәрү аркылы милли мөстәкыйльлеккә омтылуын, үз гомереннән киләчәк буыныбызга кыйммәтле мирас калдырган бөек шәхесе.

«Илебезнең бөек угылы онытылмас, хөрмәтле остазыбызның рухы, халыкның омтылышы бүген дә анык белән бер төсле икәнең тоеп шат булсын! Башта казый булып, ахырда халык теләге белән бөтен әсир төрекләрнең мөфтие булырлык, халыкның үзен-үзе идарә итәргә теләвен үзендә гәүдәләндереп килгән бердәнбер учреждение, аның вафатыннан соң да үзе белән бергә милләт-дин юлында хезмәт иткән казыйларның кулында дәвам итүен күреп, халкыбызның кызыл руслык кысалары эчендә дә сәламәт калуына күреп тыныч булсын!» – дип тәмамлый [4, 1 б.].

«Ризаэтдин бин Фәхретдин хәзрәтләре (вафатына 6 ел тулу уңаеннан)» исемле мәкаләнең авторы Бикбау. Әлеге мәкаләдә шулай ук Р. Фәхретдиннең эшчәнлегенә киң бәя бирелә.

«Хөрмәтле дин башлыгыбызның дөньядан китүе белән буш калдырылган урыны илебездәге большевик хакимиятенең авырлашып киткән

дәверләрдә дә бергәләп Диния нәзарәтебезне яшәтергә тырышып, дин галимнәребездән казый Габдрахман Зәйнулла Рәсүл тарафыннан алынган мәктүбләрдән [хат] генә беләбез. Узган алты ел эчендә диния нәзарәтебез янында нинди үзгәрешләр булгандыр бер Ходайның үзенә генә мәгълүм. Бу хакта һичбер мәгълүматыбыз юк» [2, 2 б.].

Большевиклар хакимиятенең сәясәте нәтиҗәсендә бөтенләй җимерелүгә дучар ителгән Диния нәзарәтен бу көндә бер булып саклау, автор фикеренчә, бик мөһим вазыйфа. Халкыбыз тарафыннан бик хөрмәт ителгән һәм халкыбызның даһи мирасы саклануына зур хезмәт иткән мөфти Р. Фәхретдиннең илнең зур афәтле елларында да Диния нәзарәтен саклау, аның милли һәм дини үзәк итеп калуында зур көч куюын ассызыклый.

Русия инкыйлабыннан файдаланып, илебезнең милли идарәсен үз кулларына алырга тырышкан төрки халыклар Диния нәзарәтендә зур ярдәм һәм таяныч күргәннәр. Халкыбызның үзе теләп сайлаган беренче мөфтиебез Г. Баруди туган илебезнең үз көненә үзе хуҗа булуы өчен халкыбызның милли аңын күтәрү юлында хезмәт куюы белән танылган булса, мөфти Р. Фәхретдин милләтне диннән аерган вакытта бөтен мөселман илебезнең милли иреклегенә багышлавы һәм соңгы авыр елларына кадәр үз фикерен үзгәртмәве белән зур абруйга лаек.

Үз фикерләре аркылы тарихта үз эзен калдырган Р. Фәхретдин, татар халкының бөек шәхесләре Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйрилар кебек үк, үз Ватаны өчен янып торуы, илебезнең бәйсезлек хәрәкәтендә катнашуы белән милли тарихыбызның түрендә урын алган олуглаларыбызның берсе. Р.Фәхретдин хезмәте милли тарихыбызны тикшерү, милли әхлагыбызны тирәнәйтү, милли матбугатыбызны яңарту гына түгел, хәтта милли әдәбият аланыбызда да әхлак әсәрләре белән чыккан һәм уку-укыту эшләребезгә дә бик күп өлеш чыгарган галимебез. Илебезне ирекле итәр өчен халкыбызга милли мәдәниятта үсү юлларын күрсәтүе һәм бу юлда илле ел бер буйдан эшләве Р.Фәхретдин исемен хөрмәтле милли мөхәҗирләр арасына китереп куя.

Бөтен гомерен каләм хезмәтенә багышлаган Р. Фәхретдиннең, 1917 елда Россия империясе җимерелгәч, илебезнең милли хәрәкәтендә иң күренекле урын алган, илебезгә ирек таләп иткән угларыбыздан берсе булуы мәрхүмнең хәтерен безнең өчен тагын да кадерлерәк итә.

Болардан башка, ул милли тарихыбызны кайтару, онытылып югалу куркынычыннан азат итү юлында зур көч куйган. Бу җирлектә аның эшчәнлеге бүген бөек Төркия җөмһүриятендә хаким сөрә торган милли тарих, милле телне үстерү, төркичелек фикерен тикшерү, өйрәнү омтылышы белән уртак. Р. Фәхретдин олуг милли юлыбызның тугры маяклары булган һәм төрки дөньяда танылган һәм төркичелектә зур хезмәт калдырган казанлы Йосыф Акчура, кырымлы И. Гаспралы, төрек Зыя Күк алыплары белән уртак урынны тота.

Төрек халкының милли-мәдәни барлыгын үстерү һәм туган иленең гыйльми горефен булдыру юлында актык сулышына кадәр көрәшә.

«Илебезне читләргә таныткан Р. Фәхретдин хәзрәтләренең рухы илебезнең бүген яңа мөмкинлекләр алдында торуын күреп шат булсын һәм аның исеме, хезмәтләре халык күңелендә мәңге онытылмасын», – дип тәмамлый сүзен автор [2, 2 б.].

Шулай итеп, милләт үсешенә, милли бердәмлеккә зур көч куйган Ризаэтдин Фәхретдин эшчәнлеге һәм мирасы мөһаҗирлектә яшәүче милләттәшләр арасында югары бәяләнә. Аның даны бөтен төрки, хәтта ислам дөньясында һәм Аурупа илләрендә киң таралган һәм мәгълүм булган. Ул гомер буе үзенең дини эшчәнлеген һәм фәнни хезмәтләрен туган халкының аң-белем дәрәҗәсен, әхлакый тәрбиясен күтәрү максатларына хезмәт иттерүгә багышлый. Русиядә мөфти хәзрәтенең вафаты хакында кечкенә генә бер хәбәр бирелмәсә дә, мөһаҗирлектә яши торган төркиләр өчен бу зур югалту була һәм аның кадерен югарыда бирелгән мәкаләләрдән күрергә мөмкин. Р. Фәхретдинның вафаты мөнәсәбәте белән язылган мәкаләләрнең күплеге аның олуг шәхес һәм фидакарь зат булуын дәлилли.




Рәсем 1. 1936 елның 16 сентябрендә «Әл-Балаг» (Мисыр) газетасында Р. Фәхретдин турында чыккан мәкаләдән сурәт. «Милли байрак» газетасыннан алынган (1936 елның 4 декабре).



Рәсем 2. «Милли байрак» газетасының 257 номеры (1941 елның 44 апреле).

## ӘДӘБИЯТ

1. Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. Казан: Фән, 1999. 317 б.

2. Бикбау. Ризаеддин бине Фәхреддин хәзрәтләре (вафатына 6 ел тулу уңаенда) // Милли байрак. 1942. № 306 (22). Б. 2.

3. Ерак Көнчыгыштагы төрки-татар мөһаҗирләренең мирасы («Милли байрак» газетасының библиографик күрсәткече). Казан: ТФАнең Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2015. 284 б.

4. Рокыя Мөхәммәдиш. Мәрхүм мөфтиебез Ризаетдин бине Фәхреддин хәзрәтләренең газиз рухына // Милли байрак. 1941. № 257 (20). Б. 1.

5. Тимур. Мөфти Ризаетдин бине Фәхреддин хәзрәтләре хакында ислам вә алман матбугаты // Милли байрак. 1936. № 55(5). Б. 2.

**Автор турында белешмә:** Садыйков Шамил Фәнис улы – педагогика фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, Татарстан республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); mergen777@mail.ru

# ОСВЕЩЕНИЕ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ РИЗАЭТДИНА ФАХРЕТДИНА НА СТРАНИЦАХ ГАЗЕТЫ «МИЛЛИ БАЙРАК»

***Ш.Ф. Садыков***

*Институт истории им.Ш.Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*mergen777@mail.ru*

Имя великого ученого, педагога, историка, религиозного деятеля Ризаэтдина Фахретдина известно не только в татарском, но и в мусульманском мире в целом. Область деятельности ученого многогранна и уникальна, наряду с религиозной он вел активную просветительскую и издательскую работу. В статье рассматриваются отдельные материалы о Р. Фахретдине из газеты «Милли Байрак», издаваемой в Японии в течение десяти лет (1935–1945 гг.). Политика большевиков, направленная на борьбу с религией, на долгие годы наложила табу на изучение наследия многих татарских просветителей и религиозных деятелей. В периодической печати не нашлось места даже некрологу Р. Фахретдина. Зарубежные же издания были намного свободнее в оценке происходящих процессов в России. Изучение материалов газеты «Милли Байрак» о Р. Фахретдине позволяет объективно оценить его вклад в развитие просвещения татарского народа, проследить его жизненный путь, увидеть отношение исламского мира к его деятельности и тем самым подчеркнуть его личность в судьбе татарской нации.

**Ключевые слова:** Ризаэтдин Фахретдин, муфтий, газета «Милли байрак», пресса, татарская нация, Дальний Восток, тюркский мир

**Для цитирования:** Садыков Ш.Ф. «Милли байрак» газетасында Ризаэтдин Фәхретдин эшчәнлеге яктыртылышы // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 2. С. 284–293. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.284-293

**Сведения об авторе:** Садыков Шамиль Фанисович – кандидат педагогических наук, старший научный сотрудник Центра истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); mergen777@mail.ru

## PRESENTATION OF RIZAETDIN FAKHRETDIN' ACTIVITY IN THE NEWSPAPER "MILLI BAYRAK"

***Sh.F. Sadykov***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*mergen777@mail.ru*

The name of the great scientist, teacher, historian, and religious figure Rizaetdin Fakhretdin is known not only among Tatars, but also in the whole Muslim world. His field of knowledge is multifaceted and unique, along with religious work, he conducted active educational and publishing activities. This paper discusses some materials about R. Fakhretdin from the newspaper "Milli Bayrak", which had been published in Japan for ten years (1935–1945). The policy of the Bolsheviks aimed at combating religion for many years imposed a taboo on the study of the heritage of many Tatar educators and religious figures. There was no place even for the obituary of the death of R. Fakhretdin in the periodical press. Foreign editions had more freedom in assessment of the processes occurring in Russia. The study of the materials of the newspaper "Milli Bayrak" about R. Fakhretdin gives an opportunity to objectively assess his contribution to the development of the Tatar people's education, to trace his life path, and see the attitude of the Islamic world to his activities, thus emphasizing his personality in the fate of the Tatar nation.

**Keywords:** Rizaetdin Fakhretdin, mufti, the newspaper "Milli Bayrak", mass media, the Tatar nation, Far East, the turkic world

**For citation:** Sadykov Sh.F. Presentation of Rizaetdin Fakhretdin' activity in the newspaper «Milli bayrak». Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology, 2019, vol. 4, no. 2, pp. 284–293. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.284-293

## REFERENCES

1. Abdullin Ya. *Millət jazmyshy: ujlanular* [The fate of the nation: Reflections]. Kazan, Fən Publ., 1999. 317 p. (In Tatar)

2. Bikbau. *Rizaeddin bine Fəhreddin həzrətləre (vafatyna 6 el tulu uңaenda*) [Hazrat Rizaetdin Fakhretdin (commemorating 6 years since his death)]. *Milli bajrak – National Flag*, 1942, no. 306 (22), p.2. (In Tatar)

3. *Erak Kөnchygyshtagy tөrki-tatar mөhaҗirlərenең mirasy («Milli bajrak» gazetasynyң bibliografik kyrsətkeche)* [The legacy of the Turkic-Tatar Muhajirs in the Far East (bibliographic index of the newspaper "Milli Bayrak")]. Kazan, RT Academy of Sciences Institute of History Publ., 2015. 284 p. (In Tatar)

4. *Rokyja Mөhəmmədish. Mərhym mөftiebez Rizaetdin bine Fəhreddin həzrət-lərenең gaziz ruhyna* [In memory of the deceased mufti Rizaetdin Fakhretdin]. Milli bajrak – *National Flag,* 1941, no.257 (20), p.1. (In Tatar)

5. Timur. *Mөfti Rizaetdin bine Fəhreddin həzrətləre hakynda islam və alman matbugaty* [Islamic and German press about mufti Rizaetdin Fakhretdin]. Milli bajrak – *National Flag,* 1936, no. 55(5). p.2. (In Tatar)

**About the author:** Shamil F. Sadykov is a Candidate of Sciense (Pedagogy), Senior Research Fellow of the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); mergen777@mail.ru